**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ПСЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 23 апреленнән** **№ 24**

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевскмуниципаль районының Песәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр,чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 26 декабрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» 2016 елның 23 мартындагы 25 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктың 2 нче абзацында «оешмалар)» сүзеннән соң «санлы финанс активлары, санлы валюта» сүзләрен өстәргә;

1.2. Нигезләмәнең 8 пунктындагы 3 пунктчасында «оешмалар)» сүзеннән соң «санлы финанс активлары, санлы валюта» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге Советы Рәисе В. И. Мөхәммәтгалиев